
**Шалтыравыклар.**

Бүлмәнең бер башында сызык сызыла. Анының артына 5-6 бала баса. Каршы яктагы урындыкларга шалтыравыклар куела. Тәрбияченең “Бер, ике, өч! Йөгерергә кирәк көч!” дигән сигналыннан соң, балалар каршы якка таба йөгерәләр һәм шалтыравыкны йөгереп килеп алалар, баш өстенә күтәреп шалтыраталар. Иң беренче булып йөгереп килгән бала җиңүче була.

***Бергәләп өйрәник***



***Мин сәламәт булып үсәм***

***Әти-әниләр өчен к ярдәмлек***

***(4-5 яшь)***

**Мәкальләр**

*Саф һава – тәнгә дәва.
*Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.
* Таза тәндә – таза рух.
*Чисталык – сәламәтлек билгесе.
*Шапшак – ялкауның юлдашы.

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.
Бас, кызым, эзенә,
Күз тимәсен үзеңә;
Асыл гөлләр үсеп тора.
Синең баскан эзеңә

***Табышмаклар***

Исе юк, төсе юк,

Аннан башка тормыш юк. (Су)

Лампа түгел – яктырта,

Мич түгел - җылыта Ипи түгел, су түгел,

Авыр түгел, аз түгел,

Ансыз яшәү мәмкин түгел (Һава)

Бит-кулыңны югач, сиңа мин кирәк.

Мин нәрсә булам, әйт тизрәк (Сөлге)

Шигырьләр

***Чисталык сөябез***

Иртә белән торабыз,
Битебезне юабыз.
Сабын белән юынгач,
Бигрәк матур булабыз.

Муенybызны юабыз, Тешләрне чистартабыз.
Пөхтәлекне, чисталыкны
Һәрвакыт яратабыз. Аш алдыннан һәрвакыт
Кулыбызны юабыз.
Ап-ак итеп кулны юып
Ашарга утырабыз.

Аякларны кичкырын
Сабын белән юабыз.
Юынырга яратабыз,
Без бик чиста торабыз.
Әхмәт Ерикәй

**Үстерешле уен**
**“Без урманга барган идек...”**

Балалар түгәрәктә басып торалар. Бер бала башкаларга арты белән баса. Тәрбияче күз караша белән генә түгәрәктәге бер балага ымлый. ул икенче бүлмәгә чыга. Балалар бергәләп кабатлыйлар:
Без урманга барган идек, югалттык беребезне,
Әйтеп бирче безгә, Риназ, югалттык соң без кемне?
Риназ, борылып карап, кем юклыгын әйтә. Дөрес әйтмәсә, тагын бер кат сынап карыйлар, дөрес әйтсә, урыннарын алышалар.

**Хәрәкәтле уеннар**

***Беренче булып бас***

Балалар бер-бер артлы тезелеп басалар. Тәрбияченең сигналы буенча йөгереп китәләр, йөгерү барышында тәрбияче бер баланы исеме белән атый. Исеме әйтелгән бала колоннадан чыга һәм, йөгереп, колоннаның башына барып баса. Уен шулай дәвам итә.